**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422635, РТ, Лаишевский район, село Атабаево, ул.Молодежная, д.1
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АТАБАЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422635, РТ, Лаеш районы, Атабай авылы, Яшьлэр урамы, 1 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

---

**2024 елның 8 ноябре** **224 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең Атабай торак пунктында гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегендәге Атабай торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең Атабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2024 елда үзара салым салу акчаларын 500 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә (Атабай торак пунктында Октябрь ур., Водопроводная ур. буенча)гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,
- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Атабай авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**: _________________ **Р.И.Билалов**
(имза) (имза расшифровкасы)

**Башлык-Татарстан**
**Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы:__________________ И.Х.Мусин**
(имза)(имза расшифровкасы)